**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423732, Түке авылы, Илтимер ур., 2 йорт

**СОВЕТ ТЮКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423732, село Тюково, ул. Илтимерова, дом 2

# КАРАРЫ

«27» август 2019 №20

## Актаныш муниципаль районы Түке авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Түке авыл җирлеге Советы **Карар бирә**:

1. Актаныш муниципаль районы Түке авыл җирлеге Советының 2016 елның 20 июнь10 санлы карары белән расланган, Актаныш муниципаль районы Түке авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 28 пунктның 3 абзацында «бирелә” сүзләреннән соң «бюджет һәм бюджет хисаплылыгы үтәлешен анализлаган аңа аңлатма язуы һәм дәүләт (муниципаль) йөкләмәсен үтәү һәм (яисә) бюджет ассигнованиеләреннән файдалануның башка нәтиҗәләре турында белешмәләр” сүзләрен өстәргә;

1.2. 28 пунктның 5 абзацында «бирелә” сүзләреннән соң «бюджет һәм бюджет хисаплылыгы үтәлешен анализлаган аңа аңлатма язуы һәм дәүләт (муниципаль) йөкләмәсен үтәү һәм (яисә) бюджет ассигнованиеләреннән файдалануның башка нәтиҗәләре турында белешмәләр” сүзләрен өстәргә;

1.3. 29 пунктның 1 пунктчасында "бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Түке авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

3.Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Совет Рәисе Р.М.Нуртдинов